**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сарлы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Сарлы авылы №120-60 17 декабрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендәге 70-36 номерлы «Физик затларның милкенә салым турында» карарына (2015 елның 29 октябрендәге 12-3 номерлы, 2018 елның 24 апрелендәге 91-46 номерлы, 2018 елның 13 ноябрендәге 115-57 номерлы карарлары басмасында) үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендәге 70-36 номерлы «Физик затларның милкенә салым турында» карарына (2015 елның 29 октябрендәге 12-3 номерлы, 2018 елның 24 апрелендәге 91-46 номерлы, 2018 елның 13 ноябрендәге 115-57 номерлы карарлары басмасында), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. тубэн эчтэлектэге 3.1 һәм 3.2 пунктлары өстәргә:

«3.1. Физик затлар милкенә салым түләүдән азат ителә:

1) 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнар;

2) әлеге пунктның 1 булекчәсендә күрсәтелгән гражданнарның балигъ булмаган балалары.

3.2. Салым ташламасы салым түләүче тарафыннан салым түләүченең милкендә булган һәм салым түләүче тарафыннан эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым объектына карата түләнергә тиешле салым суммасы күләмендә бирелә.

Салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасын билгеләгәндә салым ташламасы салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына карамастан салым түләүченең теләге буенча һәр төр салым салуның бер объектына карата бирелә.

Салым ташламасы, салым салуның мондый объектларында урнашкан гаражлар һәм машина - урыннардан тыш, Россия Федерациясе Салым кодексының 406 маддәсендәге 2 бүлекнең 2 бүлекчәсендә күрсәтелгән салым салу объектларына карата бирелми.

Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокукы булган физик затлар салым органына салым ташламаларын

бирү турында гариза бирергә, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документларны тапшырырга хокуклы.

Салым ташламасы бирелә торган салым салуның сайланган объектлары турында хәбәрнамә салым түләүче тарафыннан салым чоры булган һәм аннан башлап күрсәтелгән объектларга карата салым ташламасы кулланыла торган елның 1 ноябренә кадәр үзе теләгән салым органына тапшырыла.

Сайлап алынган салым салу объекты турында хәбәрнамә тапшырган салым түләүче салым чоры булып торган елның 1 ноябреннән соң күрсәтелгән салым чорында салым ташламасы куллану объектын үзгәртеп, салым органына төгәлләштерелгән белдерү кәгазе тапшырырга хокуклы түгел.

Салым ташламасына хокукы булган салым түләүче салым ташламасы бирелә торган салым салуның сайланган объектлары турында хәбәрнамә тапшырмаган очракта салым ташламасы һәр төр салым салуның иң югары исәпләнгән суммалы бер объектына карата бирелә.».

1.2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының 2018 елның 24 апрелендә кабул ителгән 91-46 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендә кабул ителгән 70-36 номерлы «Физик затларның милкенә салым турында» гы карарына (2015 елның 29 октябрендәге 12-3 номерлы карар редакциясендә) үзгәреш кертү турында" карарында:

икенче пунктта «2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми басма - «Маяк» газетасында басылып чыккан көннән бер ай узгач, үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан физик затларның милкенә салым исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла, Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә: http://aznakayevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, финанслар, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Шәрипов М.Р.